ГЛАВА КУРАЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.25, с. Куралово,
422581

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КУРАЛОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 25 нче йорт, Куралово авылы,
422581

Тел.: (84379) 33-5-36, факс: (84379) 33-5-36.

15.11.2025 № 2

КАРАР
Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Куралово авылы җирлегенең Куралово авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлегенең Куралово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә - Куралово торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (билгеләнгән урынга илтеп җиткереп, асфальт гранулят сатып алу) - юнәлтүгә сез ризамы?» дигән сорау буенча 2025 елның 15 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 813 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 421 кеше кертелгән.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 420 катнашучы тавыш бирде; «Юк позициясе өчен җыенның 1 катнашучысы тавыш бирде.
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1. Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлегенең Куралово авылы гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.
2. «Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлегенең Куралово авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегенең Куралово авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалы категориядәге гражданнардан тыш, 2026 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә - Куралово торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга (билгеләнгән урынга илтеп җиткереп, асфальт гранулят сатып алу) - ризамы?» дигән мәсьәлә буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегенең Куралово авылында гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Куралово авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Җыелышта рәислек итүче: Р.Е.Тарасов